Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, ТР, Арча ш., Совет мәйданы, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района Республики Татарстан
Совет города Арск
422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27
тел. 3-16-25, 3-12-35

**КАРАР**

« 27 » октябрь 2025 ел № 5

**Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә жирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясын, «Татарстан Республикасында жирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясын һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясын гамәлгә ашыру максатларында «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының беренче этабын 2025 елның 20 ноябрендә 15 сәг. 00 минутта Арча районы, Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 нчы йорт адресы буенча билгеләргә.

2. Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыенының икенче этабын 2025 елның 20 ноябрендә 15 сәг. 30 минутта Арча районы, Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 нчы йорт адресы буенча билгеләргә.

3. Гражданнар жыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Күпербаш авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 100 сум тәшкил иткән 80 яшьтән өлкәнрәкләрдән һәм 1 төркем инвалидлардан, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне,

мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итүдән тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Куперменбаш авылы урамнарында юл өслегенең түшәмә катламын төзү?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

4. Арча муниципаль районы Күпербаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Арча шәһәре башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны гражданнар күпләп җыела торган урында мәгълүмат стендында (Күпербаш авылы, Мичурин урамы, 10 йорт), интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге Башлыгы А.Г.Хисаметдинов